Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Нарат-Елга авыл җирлеге башлыгы
Карары

2020 елның 30 октябре №5

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Чистай муниципаль районы Нарат-Елга авыл җирлегенең Нарат-Елга авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Чистай муниципаль районының «Нарат-Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 24 ноябрендә 14.00 сәгатькә мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Нарат-Елга авыл җирлегенең Нарат-Елга авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Нарат-Елга авылы, Үзәк ур., 1а йорт.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2021 елда Чистай муниципаль районы Нарат-Елга авыл җирлегенең Нарат-Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидлардан тыш, 1000 сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризалашасызмы:

- чокырлы юлларны ремонтлау (юлларны грунтлау, вак таш сатып алу, китерү, салу, килешү буенча эш өчен түләү)

- Сосновый Ключ авылында су алу җайланмасын төзекләндерү, Нарат-Елга авылын су белән тәэмин итү челтәрләрен Сосновый Ключ авылына тоташтырып реконструкцияләү

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Җыенны оештыручы итеп Чистай муниципаль районының Нарат-Елга авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.
4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чистай муниципаль районының
Нарат-Елга
авыл җирлеге башлыгы А.Р. Хәмитов